Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы

**КАРАР № _10_**

Олы Әшнәк ав 2016 елның 20 июне

Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының "Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә җәмәгать тәртибен көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында " 2006 ел, 28 декабрь, 13 нче карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, «җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Әшнәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының «Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә җәмәгать тәртибен көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында" 2006 ел, 28 декабрь, 13 нче карарын үз көчен югалткан дип санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Р.А.Хөснетдинова

СОВЕТ
БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634001711
ОЛЫ ӘШНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ